ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
Кутузова ул., дом1,
город Лениногорск, 423250

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кутузов урамы, 1нче йорт,
Лениногорск шәһәре, 423250

Тел., факс: (8-85595) 5-19-69. Leninogorsk.Ikmo@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е        КАРАР

2024 елның «04» июле        № 1021

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 28 июненедәге 703 номерлы карары белән расланган Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында «2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,» Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 28 июненедәге 703 номерлы карары белән расланган Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.3. Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп кору һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыруны биш эш көненнән дә соңга калмыйча, күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп планлаштыруны тәмамлауны раслаучы кабул итү комиссиясе акты расланган (имзаланган) көннән башлап, торак бинаны торак булмаган

бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерүче яисә күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп коруны тәмамлауны раслаучы Башкарма комитетның вәкаләтле кешесе торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерү, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларын кулланып, хокукларны теркәү органына электрон формада мөрәҗәгать итүченең үзгәртеп планлаштырылган бинага (үзгәртеп планлаштырылган биналарга)хокукын дәүләт кадастр исәбен яки дәүләт кадастр исәбен һәм дәүләт теркәвен гамәлгә ашыру турында, кабул итү комиссиясе актының, үзгәртеп планлаштырылган биналарның техник планының һәм торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинага күчерү турындагы карарның (карар кабул итүне раслаучы документ) мондый гаризасына кушымта белән яисә күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп планлаштыруны килештерү турында, яңа биналарны үзгәртеп планлаштыру нәтиҗәсендә күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашырган өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт пошлинасы түләнүе турында мәгълүматны да кертеп, карарны (карар кабул итүне раслаучы документ) теркәп гариза җибәрә. «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13.07.2015 ел, 218-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлеше, 25 статьясында каралган нигезләр буенча дәүләт кадастр исәбен һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашыруны туктатып торган очракта, торак урынын торак булмаган бинага яки торак булмаган бинага күчерүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле зат күп фатирлы йортта бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны Килештерү яки торак бинага урнаштыру турында документлар сорый, дәүләт кадастр исәбен һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашыруны карамыйча яки туктатып тормыйча документларны кире кайтару сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле документлар, шул исәптән гариза бирүчедән (ул вәкаләтле заттан) хокукларны теркәү органына тапшыру өчен күчерелә торган һәм (яки) үзгәртеп планлаштырыла торган бинаның техник планын сорый.».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар өчен ачык булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Галимова Л.М.
5-44-72